КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 29 декабрь г.Казань № 1286

2018 елда Татарстан Республикасында Бөтенроссия конкурсының төбәк этабы кысаларында «Уңышлы мәктәп» субсидиясе рәвешендә Татарстан Республикасы бюджетыннан грант бирү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Карарга теркәлгән 2018 елда Татарстан Республикасында Бөтенроссия конкурсының төбәк этабы кысаларында «Уңышлы мәктәп» субсидиясе рәвешендә Татарстан Республикасы бюджетыннан грант бирү тәртибен расларга.
2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2018 ел, 29 декабрь, 1286 нчы
карары белән расланды

2018 елда Татарстан Республикасында Бөтенроссия конкурсының төбәк этабы кысаларында «Уңышлы мәктәп» субсидиясе рәвешендә Татарстан Республикасы бюджетыннан грант бирү тәртибе

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге Тәртип 2018 елда Татарстан Республикасында Бөтенроссия конкурсының төбәк этабы кысаларында «Уңышлы мәктәп» субсидиясе рәвешендә Татарстан Республикасы бюджетыннан грант (алга таба – грант) бирү механизмын билгели.

2. Субсидияләр рәвешендә грантлар бирү «2018 елга, 2019 һәм 2020 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2017 елның 30 ноябрендәге 85-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында каралган бюджет ассигнованиеләре һәм Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына (алга таба – Министрлык) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы мәгарифен һәм фәнен үстерү» дәүләт программасына раслау турында» 2014 ел, 22 февраль, 110 нчы карары белән расланган «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы мәгарифен һәм фәнен үстерү» дәүләт программасының «2014 – 2025 елларга гомуми белем бирүне үстерү, инклюзивны да кертеп, һәм әлеге өлкә хезмәткәрләренең квалификациясен күтәрү» ярдәмче программасы чараларын гамәлгә ашыруга бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә.

3. Грантлар Татарстан Республикасы территориясендә теркәлгән һәм үз эшчәнлекләрен билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашыручы һәм грант алуга конкурста җиңүчеләр дип танылган барлык милек формасындагы мәгариф оешмаларына бирелә (алга таба-Конкурс нигезендә сайлап алу, грант алучылар).

4. Грант бирү максатлары булып Татарстан Республикасында белем бирү сыйфатын күтәрүне стимуллаштыру һәм белем бирү эшчәнлегендә югары нәтиҗәләргә ирешүне тотрыклы тәэмин итүче мәгариф оешмаларына, аларның педагогик коллективларына ярдәм итү, мәктәп педагогик коллективының һөнәри үсеше, укыту-тәрбия процессын оештыру өлешендә оешмаларның уңай эш тәҗрибәсен тарату, социаль-мәдәни мохит булдыру тора.

Грант алучыларга педагогия коллективын һөнәри яктан үстерүгә юнәлдерелгән чараларны тормышка ашыру өчен бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләк грант булып тора.

5. Конкурс нигезендә сайлап алу турында нигезләмә Министрлык боерыгы белән раслана.

Конкурс нигезендә сайлап алу нәтиҗәләре буенча Министрлык әлеге Тәртипнең 6 пунктында билгеләнгән критерийлар буенча конкурс сайлап алуын

узган дәгъва кылучыларның I нче урыннан VIII урынга кадәр рейтингы төзелә.

6. Конкурс нигезендә сайлап алу критерияләре түбәндәгеләр:

тәкъдим ителгән мәктәпнең уңышка ирешү методикаларының һәм технологияләренең оригинальлеге;

мәктәпнең уңышлы булуын күзаллауның бөтенлеге;

тәҗрибәнең нәтиҗәлелеге һәм гамәли диссеминациясе;

оригинальлек һәм инновациялелек;

мәгълүмати культура;

үзбәяләүнең объективлыгы;

белем бирү процессында барлык катнашучыларның үзара эшләвен һәм хезмәттәшлеген күрсәтү;

мәктәпнең кыймәте юнәлешләрен (миссиясен) күзаллау;

мәктәпнең уңышына ирешүдә системалы-эшлекле һәм интерактив якын килүләр куллану.

Конкурс сайлап алу критерийларының мәгънәләре Министрлык тарафыннан билгеләнә.

7. Грантлар акчасы түбәндәгеләргә юнәлтелә:

мәгариф оешмасының педагогия коллективының һөнәри үсеше һәм квалификациясен күтәрү;

белем бирү оешмаларының эш тәҗрибәсен өйрәнү буенча семинарлар, тренинглар, җыеннар оештыру;

педагогия коллективын педагогны методик үстерүгә юнәлдерелгән матди бүләкләү.

8. Грантның максатчан билгеләнеше бар һәм грант алучы  аны әлеге Тәртиптә каралмаган максатларда файдалана алмый.

9. Әлеге Тәртип һәм конкурс сайлап алуын уңышлы узган дәгъва кылучылар рейтингы нигезендә конкурс нигезендә сайлап алу нәтиҗәләре буенча I-VIII урыннарны алган дәгъва кылучыларга 1 0000,0 мең сум күләмендә грантлар бирелә.

10. Грант Министрлык һәм грант алучы арасында төзелгән грант бирү турындагы килешү нигезендә бирелә (алга таба – килешү). Килешү формасы Министрлык боерыгы белән раслана. Килешү 2018 елда Татарстан Республикасында Бөтенроссия конкурсының төбәк этабы кысаларында «Уңышлы мәктәп» грантын түләү турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты күрсәтмәсе кабул ителгән көннән башлап эш көннәрендә исәпләнгән 30 көн эчендә төзелә.

Килешүдә түбәндәге нигезләмәләр күздә тотыла:

грантның максатчан билгеләнеше;

грантны файдалану юнәлешләре;

грант күләме;

грант бирү нәтиҗәлелеге күрсәткечләренең әһәмияте;

грантны күчерү вакытлары;

Министрлык боерыгы белән расланган форма буенча финанс тәэминаты чыганагы грант булган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисап бирү тәртибе һәм сроклары, шулай ук грант бирү нәтиҗәлелеге күрсәткечләре кыйммәтләренә ирешү турында хисап бирү тәртибе һәм сроклары;

министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан грант алучы тарафыннан аны бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүне тикшерүне тормышка ашыруга ризалык;

хисап финанс елында файдаланылмаган грантны кире кайтару тәртибе;

килешү нигезләмәләрен бозган өчен җаваплылык.

11. Грантлар килешү нигезендә билгеләнгән срокларда грант алучыларга күчерелә:

Министрлык гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен башкара торган белем бирү оешмаларыннан тыш, белем бирү оешмаларына һәм муниципаль гомуми белем бирү оешмаларының кредит оешмаларында ачылган исәп-хисап счетларына;

Министрлык гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен башкара торган дәүләт белем бирү оешмаларына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт бюджет һәм автоном учреждениеләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан дәүләт йөкләмәсен үтәүне финанс белән тәэмин итүгә бәйле булмаган башка максатларга субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибен раслау турында» 2016 ел, 30 декабрь, 1052 нче карары нигезендә Министрлык тарафыннан Финанс министрлыгында ачылган аерым шәхси счеиларына.

12. Грант алучылар Министрлыкка финанс ягыннан тәэмин итү чыганагы булып торган грант чыгымнарын гамәлгә ашыру турында хисап, шулай ук килешү нигезендә билгеләнгән формалар һәм сроклар нигезендә грант бирү нәтиҗәлелеге күрсәткечләре зурлыгына ирешү турында хисап тапшыралар.

13. Бирелгән грантлар, әлеге Тәртип белән билгеләнгән максатларны һәм шартларны бозу очраклары ачыкланган очракта, Министрлыкның тиешле таләпләрен алган көннән алып, 60 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш.

14. Хисап финанс елында файдаланылмаган грант калдыклары, килешүдә билгеләнгән тәртиптә хисап елыннан соң килүче елның 1 февраленә кадәр Татарстан Республикасы бюджеты керемenә грант алучы тарафыннан кире кайтарылырга тиеш.

15. Әлеге Тәртипнең 13 һәм 14 пунктларында күрсәтелгән срокларда Татарстан Республикасы бюджеты керемenә грант акчаларын ирекле кире кайтарудан баш тарткан очракта, алар Министрлык тарафыннан законнарда билгеләнгән сроклар һәм тәртип нигезендә мәҗбүри тәртиптә Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиеш.

16. Россия Федерациясе законнары нигезендә Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары грант алучылар тарафыннан грантлар бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүне тикшереп торалар.

17. Закон нигезендә грантны максатчан һәм нәтиҗәле файдаланган, шулай ук конкурс нигезендә сайлап алуга тәкъдим ителгән документларның дөреслеге өчен җаваплылык грант алучыга йөкләнә.

18. Грантларның максатчан кулланылышын тикшерүдә тотуны Министрлык гамәлгә ашыра.

---